ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.09.2024 г.Казань № 292-7/тко-2024

«Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү күптармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2023 елга каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик тариф билгеләү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 06.03.2024 № 8-4/тко-2024 карарының үз көчен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Югары Судының 26.04.2024 № 3а-183/2024 карарын, Гомуми юрисдикциядәге дүртенче апелляция судының 06.08.2024 № 66а-1149/2024 билгеләмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 25.09.2024 № 20-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү күптармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә әлеге карар кушымтасына туры китереп 2023 елга чик тариф билгеләргә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

3. «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү күптармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә иркле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 109 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2023 елга «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү күптармаклы җитештерү берләшмәсе»

җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик тариф билгеләү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 21.06.2023 № 69-5/тко-2023 карарын үз көчен югалткан дип тану турында» 06.03.2024 № 8-4/тко-2024 карарын көчен югалткан дип танырга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
25.09.2024 № 292-7/тко-2024
карарына кушымта

«Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү күптармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты көнкүреш калдыкларын күмүгә 2023 елга чик тариф

| Т/с | Муниципаль берәмлек, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тариф, сум/куб.метр |
|---|---|---|
| | | 2023 ел |
| | Алабуга муниципаль районы | 69,56 |
| 1 | «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү буенча күп тармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте*<br>(тариф өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге